ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

22.11.2021                                        1

с. Набережные Моркваши

Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркврашы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча

гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркрашы авыл җирлегенең 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 нче елның 3 нче декабренә Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Десятидворка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2021 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Десятидворка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Десятидворка бистәсендә урамнарны яктыртуны реконструкцияләү.

«ӘЙЕ»                    «ЮК»

3. Халык җыенын Десятидворка поселогы, Центральная урамы, 24 нче йорт адресы буенча 10.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы                    И.Х.Гаязов